**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ТҮБӘН СУЫК-СУ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

20 март 2023 ел Түбән Суыксу авыл № 6

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башкарма комитетының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре турында» 2013 елның 14 январендәге 2 номерлы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 январендагы 5-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Тукай районы прокуратурасының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләренә 2023 елның 13 мартындагы 02-08-02 номерлы протесты нигезендә һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башкарма комитеты эшчәнлеген оештыруны тәэмин итү максатында

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башкарма комитетының эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләре турында» 2013 елның 14 январендәге 1 номерлы Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 6.2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6.2. Түбән Суык-Су авыл җирлеге Башкарма комитеты хезмәткәрләренә бер ял көне (якшәмбе) белән алты көнлек эш атнасы билгеләнә. Хатын-кызлар өчен нормаль эш вакыты озынлыгы – атнага 36 сәгать, көнгә 6 сәгать 30 минут.

1.2. 6.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

6.3. Эшнең башлану һәм тәмамлану, ял һәм туклану өчен тәнәфес вакыты түбәндәгечә билгеләнә:

эш башлану - 8.00;
тәнәфес - 11.30 - 13.00;
эш тәмамлану - 16.00;
шимбә - 8.00 - 11.30.

1.3. 8.8 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Хезмәт хакы һәр ярты айдан да сирәгрәк түләнми, хезмәт хакын бирү һәм башка исәп-хисапларны башкару сроклары: агымдагы айның беренче яртысы өчен хезмәт хакы – агымдагы айның 20 числосы; соңгы түләүләр – ул исәпләнгән чор тәмамланганнан соң 5 числода.

2. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Түбән Суык-Су авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе Ф.Г.Ихсанов